**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21 ноября 2024 ел. № 488

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “Әтнә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында”гы 27.05.2019 № 161 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 14.09.2022 № 135 (18.11.2022 ел, №145, 27.01.2023 ел, №165, 15.05.2024 ел, №230, 16.11.2024 ел.№246. үзгәрешләр белән) карарына таянып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 07 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хатын үтәүдә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты **карар итә:**

1. “Әтнә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары бухгалтерлары хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында”гы 27.05.2019 ел, № 161 Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымтасының 3 нче пункты түбәндәге редакциядә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләренең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифалары | Вазифа хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе |

| | |
|---|---|
| | (бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | 31500 |
| Бүлек башлыгы | 27700 |
| Җитәкче бухгалтер | 25300 |
| Бухгалтер | 24000 |

1.2. карарга 2 нче кушымтаның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифа хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 25700 сум | 27000 сум |
| Бухгалтер | - | 24500 сум |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиевка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов